**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

Әсәй авылы № 125-65 «28» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 18 октябрендәге 52 номерлы Әсәй авыл җирлеге Советы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында 19.03.2013 №61-35, 03.06.2015 №140-74, 17.08.2018 №21, 25.02.2022 №48-24 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 18 октябрендәге 52 номерлы Әсәй авыл җирлеге Советы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә (19.03.2013 №61-35, 03.06.2015 №140-74, 17.08.2018 №21, 25.02.2022 №48-24 карарлар редакциясендә) 8.8 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«9) муниципаль милекне минималь рөхсәт ителгән бәядән сату;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.З. Дәминова.